ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендәге 10 пунктында «яисә муниципаль милеккә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^3$ һәм $9^4$ пунктлар өстәргә:
«$9^3$) мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләре урнашу урыннарының, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрын алып бару өчен билгеләнгән координаталар системасында әлеге чикләрне күрсәтә торган нокталар координаталары исемлеге белән бергә, текст рәвешендәге һәм график тасвирламасын, мәдәни мирас объектларының саклау зоналары чикләрендәге җирләрдән файдалану режимын хокукый акт белән раслау;
$9^4$) хокукларны теркәү органына Федераль законда каралган очракларда, тәртиптә һәм күләмдә белешмәләр һәм документлар юллау;»;

3) 5 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында «әлеге Законда билгеләнгән очракларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 9 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «җирле үзидарә органнары тарафыннан» сүзләрен «муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мәдәни мирас объектына аренда хокукында хуҗа булган физик яисә юридик затка ташламалы аренда түләвен билгеләү йә аренда түләвен киметү мөмкинлеге турындагы бәяләмә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан бирелә.»;

5) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларын арендага тапшырганда физик һәм юридик затларга бирелә торган ташламалар**

1. Файдаланылмый торган, торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган мәдәни мирас объектлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма хакимият органы карары белән физик яисә юридик затларга, әлеге статьяда билгеләнгән таләпләр үтәлгәндә, ташламалы аренда түләвен билгеләп, 49 елга кадәр вакытка арендага тапшырылырга мөмкин.

2. Ташламалы аренда түләве торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру нәтиҗәләре буенча мондый шартнамә төзелгән көннән билгеләнә.

3. Торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган мәдәни мирас объектларын арендага тапшыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсенең мөһим шарты Федераль законның $47^{6}$ статьясында каралган саклау йөкләмәсе нигезендә мондый мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкару буенча арендага алучының бурычыннан гыйбарәт, аларны башкару вакыты күрсәтелгән мәдәни мирас объектын арендага тапшырган көннән алып җиде елдан артмаска тиеш, моңа мәдәни мирас объектын саклап калуның аны арендага тапшырган көннән алып ике елдан артмый торган проект документациясен әзерләү һәм килештерү вакыты да керә.

5. Арендага алучы күрсәтелгән шартны үтәмәгән очракта, шартнамә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә өзелергә тиеш.

6. Торышы канәгатьләнерлек булмаган, Татарстан Республикасы милкенә караган, арендага алучыга әлеге статьяда күрсәтелгән аренда шартнамәсе буенча бирелгән мәдәни мирас объектын субарендага тапшыру, аның тарафыннан аренда шартнамәсе буенча үз хокукларын һәм бурычларын башка затка тапшыру, күрсәтелгән мәдәни мирас объектын түләүсез файдалануга бирү, аренда хокукларын залогка кую һәм аларны мөлкәт кертеме буларак коммерциячел булмаган

оешмаларга яисә пай кертеме буларак җитештерү кооперативларына кертү рөхсәт ителми.

7. Торышы канәгатьләнерлек булмаган, муниципаль милеккә караган мәдәни мирас объектлары өчен, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртипкә нигезләнеп, ташламалы аренда түләве билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 28-ТРЗ